ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур.,16 нче йорт, Килди авылы,
422586

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30.11.2023 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 47

с. Кильдеево

## Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы нигезендә Килди авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенында кабул ителгән 2022 елның 26 октябрендәге 1 номерлы карарны гамәлгә ашыру максатларында Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге башлыгы — Бурдин В.М
.

Килди авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 30
ноябреннән 47 номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 1.01.2024 елдан 25.03.2024 елга кадәр гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары.

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:
а) уку йортлары студентлары,
б) күп балалы гаиләләр.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.
Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки кечерәйтелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Килди авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар түләүләрне физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисаплар башкару хокукына ия булган оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яки https://uslugi.tatarstan.ru/. сылтама буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша күчерү юлы белән башкара ала.

8. Түләү фактын раслау булып керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Килди авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 30
ноябреннән 47 номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү турында

Түләүченең Ф.И.А.и.
____________________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________
___________________________________________________________ нигезендә
сезгә ______ кадәр чараларны гамәлгә ашыру өчен _____ күләмендә
түбәндәге реквизитлар буенча:
_____________________________________________________________бер тапкыр
түләү түләргә кирәк.
Алучының банкы БИК ___________________________________________
Сч. № __________________________________________________
Алучы __ Сч. № __________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________________ОКАТО ______________________
Түләү билгеләү
_______________________________________________________________________

Җитәкче _________________________________________________
М. у. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)
- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -
Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне бюджетка түләү турында
__________________
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә.

Түләүченең Ф.И.А.и. _____________________________
Адрес: ________________________________________________

Алдым "__" __________________ 20____ ел _ ___________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Әгәр хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырыла икән, киселә торган өлеше тутырыла һәм Килди авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.